РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024 ел г. Альметьевск № 2195

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Әлмәт муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмнәрен күтәрү турында, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсендә эшләүче аерым оешмалар хезмәткәрләренең Бердәм тариф челтәре аларга кагылмый торган хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган Әлмәт муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәте хакы түләү шартлары турында» 2018 елның 25 июнендәге 864 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 1827 номерлы, 2022 елның 28 гыйнварындагы 99 номерлы, 2022 елның 17 мартындагы 419 номерлы, 2022 елның 26 сентябрендәге 2102 номерлы, 2022 елның 28 октябрендәге 2489 номерлы, 2022 елның 21 декабрендәге 3088 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктындагы 3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

заказ № 1-851

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» июнь 2018 ел № 864
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Әлмәт муниципаль районы бюджет өлкәсендә аерым оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи окладларның күләме, сум |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 18 120 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 17 587 |
| Бүлек җитәкчесе | 16 921 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 16 121 |
| Баш белгеч | 15 322 |
| Алып баручы белгеч | 14 523 |
| I категорияле белгеч | 13 590 |
| II категорияле белгеч | 13 457 |
| Белгеч | 13 323 |

1.3. Карарга 2 нче кушымтадагы таблицада «12 688» санын «13 323» саннарына алмаштырырга.

2. Бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренә аерым оешмалар хезмәткәрләренең өстәмә түләүләрен һәм башка түләүләрен билгеләү турында элек чыгарылган актларны әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Р06-12061/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1644035822
КПП 164401001
ОГРН 1051605067172